ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 457 от «19» 04 2017 г.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районында
2016/2017 елларның җылыту
чоры тәмамлану турында

Тышкы һаваның уртача тәүлеклек температурасы муниципаль учреждениеләрдән җәйге режимда файдаланырга мөмкинлек бирә торган булып торыклануы сәбәпле, «Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге № 190-ФЗ Федераль закон (29.12.2014 елгы редакциядә), «Күпфатирлы йортларда һәм торак йортларда биналарның милекчеләренә һәм файдаланучыларына коммуналь хезмәтләр күрсәтү турында» 2011 елның 6 маендагы № 354 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә, Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты турындагы Нигезләмәгә таянып, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты

к а р а р б и р ә:

1. 2016/2017 елларның җылыту чорын 2017 елның 24 апреленнән тәмамларга.

2. Тәкъдим итәргә:

- ААҖ «Мамадыш җылылык челтәрләренә» (Миннахметов Р.Р.), үз балансында котельный һәм социаль-көнкүреш билгеләнештәге торак-коммуналь объектлар булган оешмаларга, объектларны техник эксплуатацияләү кагыйдәләре һәм нормалары нигезендә, җылылык сезонын тәмамлау белән бәйле чараларны үтәргә.

- ААҖ «Мамадыш җылылык челтәрләренә» (Миннахметов Р.Р.) җылы һава торышы торыклы башланганчы, кинәт суык булган очракларда, беренче чиратта, сәламәтлек саклау объектлары һәм балалар учреждениеләрендә, автоном җылылык чыганакларының һәм үзәк җылыту системаларының әзерлеген тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының «Мамадыш муниципаль районында 2016 -2017 елларның көзге-кышкы чорының җылыту сезоны башлану турында» 2016 елның 13 сентябрендәге 1109 санлы карарын гамәлдән чыккан дип танырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен үз контролемә алам.

Җитәкче И.Э.Фәттахов